Татар шигърияте тарихында Башкортстан җирлеге мөһим роль уйный. Гасырлар буена тел-лөгать һәм әхлак алмашып гомер иткән татар һәм башкорт халыклары бер-берсенең әдәби һәм мәдәни күтәрелешенә зур йогынты ясый. Гаҗәеп гүзәл табигате һәм иркен далалары булган Урал буйлары татар әдәбиятын шигъри җанлы иҗат көчләре белән туендырып торган. «XIX – XX гасырларга гына күз салыйк, – дип яза Башкортстанда яшәүче татар шагыйре Ф.Габдерәхим. – Бу чорда бүген Башкортстанга кергән җирләрдә бик күп каләмзатлар әдәби иҗат белән шөгыльләнгән. Аларның иң күренеклеләре – Мәҗит Гафури, Сәйфи Кудаш, Шәмсетдин Зәки, Шәехзадә Бабич, Дәрдемәнд, Сәгыйт Рәмиев, Ярлы Кәрим. Бу исемлекне дәвам итәргә була, әлбәттә. Алар барысы да татар телендә иҗат иткән» [1: 54]. Гомерен республикада татар китабын бастыруга һәм пропагандалауга багышлаган фидакарь зат Д.Морзакаева билгеләвенчә, «1921 – 1926 нчы елларда «Башкнига» нәшриятында җәмгысе 232 исемдәге китап дөнья күрә, шуларның 190 ы – башкортча, 10 исемдәгесе – русча, 32 исемдәгесе татар телендә була» [2: 8]. Әмма сәяси-җәмгыяви җилләр, тормыш-яшәешне фәлсәфи һәм эмоциональ яссылыкта кабул итеп, татар әдәбиятын талантлы затларга баеткан бу әдәби багланышка тискәре йогынты ясый: «Милли әдәбият һәм мәдәниятләрне автономияле республика кысаларына гына дыңгычлап кертү нәтиҗәсендә, Уфада татар телендә китап нәшерләү туктатылды, журналлар татар телендә басылмый башладылар <…>. Нәтиҗәдә туган җиреннән аерылырга теләмәгән байтак әдипләр башкортча иҗат итүгә яисә китапларын шул телдә чыгаруга күчте» [3: 296]. Н.Исәнбәт, Х.Кәрим кебек язучылар Татарстанга күчеп китсәләр, М.Гафури, С.Кудаш, Г.Гомәр туган-үскән җирләрендә яшәп иҗат итүне артыграк күрәләр. Алар Башкортстандагы татар язучылары дип йөртеләләр. Әмма 1934 елда СССР Язучылар берлеге, аннан Башкортстан Язучылар берлеге төзелеп, язучыларның шул

рәсми оешмаларда торырга тиешлеге мәҗбүри төс алгач, акрынлап әлеге татар язучылары башкортныкы дип атала башлый (М.Гафури 1934 елда вафат була, димәк ул дөнья белән татар язучысы сыйфатында хушлашкан). Тора-бара аларның кайберләре шушы хәлгә күнегә. Татар телендә китап чыгару мөмкинлеге булмау да шуңа этәрә [4: 237-238].

Иҗат юлын Башкортстанда башлап, әсәрләрен туган телдә бастырудан мәхрүм ителгән татар шагыйрьләре 1920 – 1980 елларда Казанга күпләп күченә яисә иҗат теле итеп башкортчаны сайлый. Бу процесс Көнбатыш Башкортстан мисалында, күренекле галим Р.Сибәгатов тарафыннан, тарихи планда күздән кичерелеп, җентекле анализлана. Башкорт теле гамәлгә куелып, милли матбугат, китап басу барлыкка килгән 1920 елларда 15 ләп язучы иҗатка килә. Шуларның 11 е – татар әдәбиятының күренекле вәкилләре Ярлы Кәрим (Бишбүләк), Мирсәй Әмир (Мәләвез), Әмирхан Еники (Благовар), Әхмәт Ерикәй (Дуван), Риза Ишморат (Яңавыл), Фатих Кәрим (Бишбүләк), Гази Кашшаф (Туймазы), Галимҗан Нигъмәти (Чишмә) һәм башкалар. Җирле мөмкинлектән файдаланырга булган Али Карнай, Гариф Гомәр кебекләр башкорт язучылары дип йөртелә.

1930 елларда каләм тибрәтә башлаган 25 ләп язучының унбише, республикада калып, башкорт әдәбиятының күтәрелешен тәэмин итәләр: Ибраһим Абдуллин (Шаран), Тимер Арслан (Туймазы), Әкрам Вәли (Чакмагыш), Йосыф Гәрәй (Шаран), Рәис Габдрахманов (Благовар), Мостай Кәрим (Чишмә), Хәниф Кәрим (Кыйгы), Мөслим Марат (Борай), Хәсән Мохтар (Кушнаренко), Кирәй Мәргән (Мишкә), Бәдрүш Мокамай (Дүртөйле), Нажар Нәҗми (Дүртөйле), Мәлих Харис (Чакмагыш), Әхнәф Харисов (Балтач), Гайнан Әмири (Яңавыл) һәм башкалар. Унга якыны – Әлшәйдән Касыйм Вахит, Кушнаренкодан Лотфый Вәли белән Мин Шабай, Туймазыдан Хәйретдин Мөҗәй, Чакмагыштан Нур Гайсин белән Галимҗан Латыйп, Чишмәдән Рәхим Саттар, Кыйгыдан Исмәгыйль Шәфиевләр – әдәби-мәдәни эшчәнлекләрен Татарстанда дәвам иттерәләр.

1940 елларда Башкортстан татарларыннан һәм көнбатыш башкортларыннан сигез язучы Казанда, биш язучы Уфада танылып өлгерә. Яңавылдан Әдип Маликов, Нурихан Фәттах, Сәет Кальметов беренче төркемдә. Аларга Зыя Мансурны (Дүртөйле) һәм Мәҗит Рәфыйковны (Күгәрчен) өстәргә кирәк. Туган якта торып калучылар арасында Гыйлемдар Рамазанов, Габдулла Әхмәтшин, Әнвәр Бикчәнтәев, Динис Исламов, Нәҗип Асанбаев та бар. 1950 еллар башында әдәбиятка килеп, Казан белән Уфа арасында рухи сукмак салган Әнгам Атнабаев та шушы төркемгә керә.

Р.Сибәгатов узган гасырның икенче яртысында кулына каләм алган якташларыбызның ким дигәндә өчтән беренең, Казанга китеп, туган телләрендә иҗат итүләрен тенденция буларак ассызыклый. 1950 елларда 15 кешенең бишесе (арада Нил Юзиев белән Илдар Юзеев бар); 1960 елларда 20 кешенең җидесе (Илештән Әхсән Баян һәм Хәсән Сәрьян, Кыйгыдан Резеда Вәлиева, Яңавылдан Саҗидә Сөләйманова, Нуриманнан Зиннур Насыйбуллин, Кушнареннан Рәдиф Гатауллин, Әлшәйдән Әмир Мәхмүдов), ягъни барысы да иҗат активлыклары белән аерылып торган талантлы шагыйрьләр, прозаиклар; 1970 елларда 14 кешенең бишесе (Благовардан Нурия Измайлова, Илештән Роберт Миңнуллин, Ярмәкәйдән Ризван Хәмид, Бакалыдан Ләис белән Фәиз Зөлкарнәевлар) Казанга юл ала. Мәкалә авторы, үз күзәтүләренә нәтиҗә ясап, татарча сөйләшүче Көнбатыш Башкортстанның, мәдәният җәһәтеннән икегә өзелеп, бер өлеше – Казан, икенче өлеше Уфа ягында калуын ачынып искәртә [5: 67-69]. Шулай итеп, хакыйкать ни кадәр ачы булмасын, «башкорт һәм татар әдәбиятлары – Башкортстандагы татар әдәбиятының ике канаты» [1: 54] булып тора.

1980 елларның икенче яртысында илдә кискен иҗтимагый-рухи үзгәрешләр башлангач, милли үзаң үсеше нәтиҗәсендә, Башкортстан татарларының әдәби-мәдәни тормышына республика җитәкчелегенең мөнәсәбәте үзгәрде. Бу, беренче чиратта, татар телендә вакытлы матбугат чыгару, әдәби китаплар нәшер итүдә күренде. Мәсәлән, совет чорында Башкортстанда татар телендә нибары «Кызыл таң» газетасы гына дөнья күрсә, 1991 елда дәүләт хисабына – «Өмет» яшьләр газетасы, 1994 елда республика татарларының әдәби үзәге дәрәҗәсендәге «Тулпар» журналы басыла башлады. Аның битләрендә канат ныгыткан талантлы авторлар бүген Башкортстандагы татар әдәби барышының әйдәп баручы көчләрен тәшкил итә.

«Китап» нәшриятында Башкортстан халыклары әдәбияты секторы, Башкортстан Язучылар берлегендә татар иҗатчылары берләшмәсе оештырылуы белән республикада

яшәүче милләттәшләребез үз әсәрләрен туган телдә бастыру мөмкинлеген алдылар. Кыска гына вакыт аралыгында Башкортстанда татар телендә иҗат итүчеләрнең зур төркеме барлыкка килеп, ул үз эченә, Әнгам Атнабаев, Марат Кәримов кебек аксакал шагыйрьләр белән бергә, иҗатка яңа аяк баскан Руслан Сөләйманов, Ләйсән Якупова, Нурлан Ганиев, Илүсә Исмәгыйлеваларны алды. Татар телендә күләмле шигъри җыентыклар, дистәләрчә поэмалар дөнья күрде. Зәйнәп Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшриятында 1994 – 2005 еллар аралыгында гына да «татар телендә 133 басма, шул исәптән 97 әдәби китап һәм 36 дәреслек дөнья күрде» [6: 57]. 2016 ел башына әлеге матбагада 115 е – шигърият, 83е проза жанрларына караган барлыгы 210 китап татар телендә нәшер ителә. Шул исәптән, нәшриятта, сектор оештырылган 1994 елдан алып бүгенге көнгә кадәр, төрле әдәби жанрларны берләштергән 12 җыентык та татар телендә басылып чыккан.

Башкортстандагы татар әдәбияты һәм шулай ук поэзиянең идея-эстетик үзенчәлекләрен, үсеш тенденцияләрен билгеләүдә әдәби тәнкыйть мәгълүм роль уйный. Төрле буын галимнәре һәм тәнкыйтьчеләрендә бу мирас зур кызыксыну уята. Әлеге эзләнүләрнең максаты булып, Башкортстандагы хәзерге татар поэзиясенең тәнкыйтьчеләр рецепциясендә яктыртылышын өйрәнү тора. Совет чорында, сәяси һәм идеологик максатлардан чыгып, бер-берсеннән ераклашуга дучар ителсәләр дә, ике төбәктәге сүз сәнгате бер тамырдан үсеп чыккан әдәбиятлар булып тора: «Башкортстандагы милләттәшләребез иҗатын гомумтатар әдәбиятының үзенчәлекле, әмма аерылгысыз бер тармагы, бер дисбенең төймәләре итеп карарга кирәк. Бу иҗатчылар татар халкы арасыннан чыккан, аның мәдәни-тарихи мирасын һәм бүгенге үсешен яктыртуны бурыч иткән» [7: 110]. Үзгәртеп коруларга кадәр, нигездә, әдәбият тарихы проблемалары белән шөгыльләнгән К.Дәүләтшин, С.Сафуанов, С.Хафизов, Р.Әмиров, М.Мөлековлар, беренчеләрдән булып, Башкортстандагы татар шигъриятенең иҗат юнәлешләрен, аның төбәк үзенчәлекләрен ачыклауга алынып, язучыларның иҗат лабораториясенә үтеп керәләр.

Тәнкыйтьчеләр, иң беренче нәүбәттә, «әдәби төбәк шигъриятенең поэтик үзенчәлекләрен ачыклау» [8: 5] мәсьәләсенә үз игътибарларын юнәлтәләр. Әдәбият галиме К.Дәүләтшин фикеренчә, «Башкортстандагы татар әдәби хәрәкәтен күзаллау өчен, иң беренче чиратта, шагыйрьләрнең стиль аерымлыгына игътибар итәргә тиешбез. Чөнки әдәби хәрәкәт ул – кабатланмас шәхесләр эшчәнлегенең нәтиҗәсе» [8: 13]. С.Хафизов иҗат кешесенең индивидуаль стиль билгеләре аның әдәби хәрәкәттәге урынын төгәлрәк ачыкларга ярдәм итә дигән караштa тора: «Әдәбиятның өлгерү-җитлегү дәрәҗәсен галимнәр язучыларның стиль ачыклыгы һәм аның төрлелеге, байлыгы белән билгелиләр. Башкортстанда үзенең каләм үзенчәлекләрен ачкан дистәгә якын татар язучысы бар. <…>. Алар үз шигъри дөньясын, үз юлын, үз тавышын тапкан шагыйрьләр» [9: 24]. Шулай итеп, галимнәр Башкортстандагы татар шигъриятенең төбәк үзенчәлекләрен билгеләүгә биредә иҗат итүчеләрнең шәхсиятле стиль үзенчәлекләрен ачыклау аша киләләр.

«Стиль» төшенчәсе әдәбият белемендә берничә мәгънәдә кулланыла. «Стиль – заман рухын, теге яки бу әдәби агым яки юнәлешнең эстетик принципларын, авторның дөнья карашын белдерүче әдәби алымнар системасы. Шәхси стиль – автор катнашуын әдәби әсәрдәге барлык әһәмиятле элементларда (композиция, интонация, тел чаралары системасында) турыдан-туры белдерү» [10: 180]. «Үзенчәлекле сурәт алымнары һәм чаралары, әдәби әсәрнең компоновкасы, аның кабатланмас архитектоникасы индивидуаль стиль билгеләре булып торалар. Чөнки һәр конкрет әчтәлек билгеле бер стиль һәм үзенчәлекле форма тудыручы принцип таләп итә» [8: 6]. Ф.Хатипов карашынча, авторның фикерләү үзенчәлеге стиль нигезен барлыкка китерә [11: 291].

«Чор стиле («олы стиль») – әдәби алымнар системасының билгеле бер мәдәни-тарихи вакытта барлыкка килүче һәм бу заманга хас булган дөньяга мөнәсәбәтнең гомуми принципларына нигезләнүче инвариантлары» [10: 180]. Чор стиле мәгънәви яктан әдәби төбәк стиле белән күпмедер күләмдә туры килә. Бер вакыт аралыгында, бер географик һәм рухи-әдәби мохиттә яшәп, бер телдә иҗат итүчеләрнең әсәрләре субъективлык-объективлык, сурәтләү-мөнәсәбәт белдерү, монументальлек-тарлык категорияләре, әдәби шартлылык тибы ягыннан тәңгәл килүе дә моңа нигез булып тора.

Башкортстандагы татар шигърияте, аның төбәк үзенчәлекләре, каләм әһелләренең сыйфатлары турында фикер йөрткәндә, буыннар мәсьәләсе мөһим аспект булып тора. Дәһшәтле сугыш елларында, яисә Сталин дәверендә дөньяга килеп, шул чорда хакимлек иткән идеологик карашлар һәм мәдәни шартларда тәрбияләнгән өлкән буын вәкилләре белән «үзгәртеп кору» яки 1990 еллардагы милли үзаң күтәрелеше чорында шәхес буларак формалашкан каләм әһелләре арасында дөньяны күзаллауда, аны поэтик гәүдәләндерү алымнарында аерма шактый зур.

Мәсәлән, шагыйрь М.Вафин тәнкыйтьче С.Хафизов белән бәхәстә, Башкортстанда татар телендә иҗат итеп, үзләрен татар шагыйрьләре дип санаучыларны дүрт буынга аера: «Әйтик, өлкән буыннардан бу сафка Фәрит Габдерәхим, Рәшит Гатауллин һәм Рим Идиятуллинны кертер идем, – ди ул. – Урта буында Салават Рәхмәтулла, Рәдиф Тимершин, Марис Назировлар. Яшьрәк буынга Мөнир Вафинны, Марат Кәбировны һәм Рамил Чурагуловны кертәм, һәм иң яшь буын дип Илдус Фазлетдинов, Илфак Фаризов, Илдар Фазлетдинов, Рәзиф Зөбәеровларны атарга була» [9: 23]. М.Вафин хатын-кыз шагыйрәләрне аерым катлам буларак карап, алар исәбенә Дилә Булгакова, Халисә Мөдәрисова, Нәҗибә Әминева, Рафига Усманова, Кәүсәрия Шәфыйкова, Нәфисә Хабибдиярова, Гүзәлия Тимершина, Әлфия Булат кебек каләм әһелләрен кертә [9: 23]. XXI гасыр башында киң танылу яулаган Л.Сәгыйдуллина, Ф.Габидуллина, З.Салихова, Ф.Максютова, Ф.Харрасова, Л.Якупова, Р.Сөләйманов, Н.Ганиев, И.Исмәгыйлеваларның килүен күздә тотсак, Башкортстандагы татар шигъриятен әйдәп баручыларның шактый тулы картинасы барлыкка килә.

Татар әдәбиятының һәрдаим тормышка якын торып, халык һәм милләт язмышын үзәктә тотуы аның реалистик һәм романтик юнәлешләрдә үсүен билгели. Башкортстандагы татар поэзиясе дә бу хәрәкәттән аерылгысыз. «Иҗат иясенең индивидуаль стиле тормыш фактларын образлы эшкәртүгә генә кайтып калмый, – дип яза К.Дәүләтшин. – Аның чынбарлык материалын сайлап алу, танып белү һәм сәнгатьчә бәяләү принцибында ук күренә. Бу күзлектән караганда, Башкортстандагы татар шагыйрьләренең иҗат методы бер үк – кырыс реализмның романтика белән тыгыз үрелгән бер төре дияргә мөмкиндер» [8: 8]. «Яшәешнең, кешеләр табигатенең асылын, төс һәм төсмерләрен бөтен нечкәлекләренә кадәр төгәл, дөрес итеп гәүдәләндерү»не [11: 246] максат итеп куйган реалистик иҗат тибы «чынбарлыкны хыялдагыча үзгәртеп, күтәренке итеп сурәтләү»гә [11: 246] нигезләнгән романтизм принциплары белән бергә үрелеп китә.

К.Дәүләтшин «шагыйрь иҗатының үзәгендә яткан, аның иҗатын системалы бер бөтен итүче шәхсиятле үзенчәлекләр» [8: 6] ноктасыннан Башкортстандагы татар шагыйрьләре иҗатына күзәтү ясый. Р.Идиятуллин әсәрләренең сәнгатьчел гүзәллеге шигъри сурәт иҗат итүнең төрле принципларын синтезлаган рәссамлык осталыгында, М.Назировның поэтик уңышы туган җир, туган халык тойгысының, тирән хис һәм олы фикернең нечкә моң аша бирелүдә күрсәтелә. М.Вафин шигъриятендә образлылык принциплары һәм сурәтле фикерләү нигезендә, новеллизмга хас сыйфатлар чагылуы, С.Рәхмәтулла поэзиясендә хәлиткеч рольне, шигъри образдан бигрәк, поэтик фикер тәшкил итүе, М.Кәбиров шигырьләренең исә поэтик камиллек, эчтәлек һәм форма гармониясе белән укучы күңелен җәлеп итүе ачыкланса, Ф.Габдрәхим әсәрләрендә йөрәк хисләренә манчылган публицистик рухның шигъри образлылык тукымасында сәнгатьчел яңгыраш алуы, Р.Чурагулов шигъриятендәге гадилек, гадәтилекнең үтемле эстетик чара дәрәҗәсенә үстерелүе аерылып чыгарыла. М.Закировка «бер минутлык мизгелдән моңсу бер матур сурәт тудыру, фәлсәфи йомгак ясау» хас булса, Х.Мөдәрисова лирикасыннан самими сафлык, ихласлык бөркелеп тора. Л.Сәгыйдуллина иҗаты «йөрәк акылына» манчылган, «әрнеткеч сагыш һәм сабыр ярсулы», көндәлек могҗизаларга гаҗәпләнүче интеллектуаль лирика буларак бәяләнә [8: 6-7].

Мәкалә авторы карашынча, индивидуаль стиль – чор стиле, әдәби төбәк стиле, милли стильләр белән тыгыз бәйләнгән, чөнки шәхси иҗат стиле аерым язучының үз табышы гына түгел, ә иҗтимагый тирәлеккә бәйле рәвештә билгеле бер заман, әдәби төбәкнең идея-эстетик казанышы да. Шуңа да иҗат принциплары (иҗат методлары) уртаклыгы Башкортстандагы татар шагыйрьләрен берләштерүче әдәби төбәк стиленә хас сыйфатларны күзалларга мөмкинлек бирә. Төбәк лирикасындагы уртак билгеләр тормыш-көнкүреш, иҗтимагый һәм табигый тирәлек берлегеннән килә. Еш кына алар иҗатында, кабатланмас үзенчәлекләрдән бигрәк, конкрет төбәктәге әдәби юнәлешкә хас

гомуми стиль билгеләре өстенлек итә. Шушы хасият төбәк шигърияттен Татарстандагы әдәби хәрәкәттән аермалы итә. Мәсәлән, Башкортстандагы татар поэзиясендә Туган ил, Ватан тойгысы, гражданлык пафосы башка. К.Дәүләтшин Башкортстан җирлегендәге татар әдәбияты Казан, татар милли әдәби хәрәкәте белән бердәм агым түгел, җирле шигъриятнең шактый үзенчәлекле, күпмедер дәрәҗәдә мөстәкыйль әдәби юнәлеше, төбәк әдәбияты дигән караштa тора [8: 16-17].

Әлеге фикерен ул Башкортстанның Кушнаренко районы Марс авылында туып, берсе – Казанда, икенчесе Уфада яшәп иҗат итүче ике бертуган шагыйрь – Рәдиф Гаташ һәм Рәшит Гатауллин әсәрләрен анализлау аша расларга омтыла. Төбәк шигъриятенә хас бер үзенчәлекне шагыйрь кальбендәге көрәш, ягъни «туган җир һәм изге Ватан тойгысы» арасындагы каршылык хисе барлыкка китерә.

| | |
|---|---|
| *Уфа – Казан... Гомер буе сызлар* | *Казанда соң мине кем көтә?* |
| *Йөрәктәге олы яра син,* | *Тукай рухы, Сибгат, Туфан рухы –* |
| *Уфаларда ятим итсәләр дә,* | *Гомер буе шулар җилкетә, –* |

дип яза Р.Гатуллин.

Тарихи Ватан – Тукай, Сибгат, Туфаннар рухы булып конкретлашкан Татарстан – күренмәс җепләр белән, шагыйрьне һәрчак үзенә тарта, әмма аңа туган якка мәхәббәт хисе каршы төшә.

*Казаннарга барсам, Казан мине*
*Үги итмәс иде, чит итмәс, –*
*Чәрмәсәнем, Кармасаным гына*
*Ничек ташар икән мин киткәч* [8: 10-11].

Мәгълүм булганча, лирик герой күңелендәге каршылык сәяси-иҗтимагый һәм тарихи сәбәпләр белән аңлатыла. Октябрь инкыйлабыннан соң, милли республикалар оешкач, күрше төбәкләрдә бүленеп калу сәбәпле, башка әдәбиятка хезмәт итәргә мәҗбүр ителгән татар әдипләре гомер буе рухи кыйбла Казанны сагынып, аңа омтылып яши. Тарихи Ватан – Татарстан – ничек кенә үзенә тартып тормасын, туган җир – Башкортстан туфрагы да – шул дәрәҗәдә изге. Башкортстанның халык шагыйре Ә.Атнабаев капма-каршылыкка нигезләнгән бу бердәмлекне поэтик параллельләр аша оста сурәтли:

*Казанны сагынып барам да*
*Уфамны сагынып кайтам* [12: 58].

Тарихи Ватанга мәхәббәт хисе көчлерәк булып, Казанда туган телдә иҗат итү мөмкинлеге бирелсә дә, шагыйрь күңелендәге туган җирне, кендек каны тамган туфракны сагыну аны гомер буена озата бара. К.Дәүләтшин, моны дәлилләү өчен, Рәдиф Гаташ шигъриятенә мөрәҗәгать итә:

*Мин Казанда бүген.*
*Сорау:*
*Бәхетен таптымы икән йөрәгем?*
*Күңелемнән ничә кабатладым*
*Юккамыни килеп йөргәнмен?! –*
дип үз-үзенә сорау бирә шагыйрь.
Икенче бер шигырендә ул:
*Туган туфрагыңнан аерылсаң,*
*Гомереңнән синең ни мәгънә? –*
дип, лирик герой күңелендәге катлаулы көрәш коллизияләрен ачып сала [8: 13-14].

Шул ук вакытта энесе Рәдифкә багышланган «Мин озатам сине» шигырендә Рәшит Гатауллин болай ди:

*Китәм дисең инде Казаныңа,*
*Син китәсең... Миңа каласы,*
*Сәер бер хис җанда, әйтерсең мин*
*Үз җиремнең үги баласы* [8: 15].

«Мисаллардан күренгәнчә, агалы-энеле шагыйрьләр иҗатында гражданлык пафосы, «Туган ил», «Ватан» тойгысы шактый үзенчәлекле яңгыраш таба. Бер үк ана балалары, бер үк чишмә суын татып үскән замандаш шагыйрьләр стиленә иҗтимагый-сәяси тирәлек, төбәк үзенчәлеге хәлиткеч эз сала» [10: 16]. Димәк, тарихи Ватаннан, туган тел мохитеннән читтә яшәү – туган туфрактан аерылу кебек үк, иҗатчы фаҗигасе ул. Бу фәлсәфи фикер Л.Сәгыйдуллинада тагын да пафослырак яңгырый:

| | |
|---|---|
| *Илле илсез,* | *Без бу илдә.* |
| *Телле телсез* | *Барлы-юклы* |
| *Без бу җирдә.* | *Без бу җирдә...* |
| *Хаклы хаксыз,* | *Бармы-юкмы* |
| *Җырлы җырсыз* | *Без бу илдә?* [13: 321-322]. |

Шагыйрә Х.Мөдәрисова шигъри юлларында әлеге фикерне башка калыпка салып бирә:

*Сөекле зат булалмадым Сиңдә,*
*Ни кылсам да күңел кителде,*
*Үз өеңдә үги ана белән*
*Үсеп килгән бала шикелле* [8: 12].

«Телле-телсезлек», «үз иленең үги баласы» кебек мотивларга нигезләнеп, К.Дәүләтшинның,

Башкортстандагы татар шигърияте гомумтатар әдәби барышыннан аерып, мөстәкыйль агым итеп карау омтылышы гыйльми һәм әдәби даирәләрдә кызу бәхәсләр тудырды. Берәүләр, аны хуплап чыгып, төбәк шигъриятенең яңа үзенчәлекләрен ачыкларга тырышса, икенчеләр тарафыннан бу караш татар халкының рухи асылын – шигъриятен, моңын – кисәкләргә бүлгәләү максатын куйган «әдәби сепаратизм» чагылышы буларак бәяләнде. Шул уңайдан «Тулпар» журналында ике ел дәвамында барган «Башкортстан татар шигърияте: торышы һәм киләчәге» дигән сөйләшүдә фикер алышу мәйданына өч сорау чыгарылды:

1. Башкортстандагы татар шигъриятенең торышын һәм үсеш юнәлешләрен ничек бәялисез?

2. Гомумтатар шигъриятендә аның урыны нинди, төбәк үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?

3. Әдәби тәнкыйтьтә Башкортстандагы бүгенге татар шигъриятенең яктыртылышы ни дәрәҗәдә дип исәплисез? [14: 54]

Сөйләшүгә йомгак ясаган «Бәхәс тәмам» редакция мәкаләсендә фикер алышуда әдәби җәмәгатьчелекнең активлыгы ассызыклана, журнал адресына 12 язма килеп, шулар арасыннан уңышлы дип табылган унбер мәкаләнең басылып чыгуы билгеләнә [15: 36].

Әдәби бәхәсне ачып җибәргән шагыйрь Ф.Габдерәхим шактый үзенчәлекле фикер әйтә: «Башкорт һәм татар әдәбиятлары – Башкортстандагы татар әдәбиятының ике канаты. Ул үзенең тамырлары белән бай тарихлы туган әдәбиятыбызга барып тоташа. Шул ук вакытта башкорт әдәбиятының йогынтысын да инкяр итеп булмый. Менә шушы хәл республикабыздагы татар әдәби иҗат җимешләренең үзенчәлеген барлыкка китерә дә инде» [1: 54-55]. Ике халык әдәбияты арасында күпер ролен башкарган татар әдәбияты, аның карашынча, төп татар рухын саклаган хәлдә, башкорт әдәбиятының кобаер, чәчән җыруларын, озын җырларын, шушы халыкныкы гына булган дастаннарын, экиятләрен, андагы образларны, символларны күпмедер дәрәҗәдә файдалана. Язма авторы сүз сәнгатендә өстенлек иткән хисне дә башкорт әдәбиятының йогынтысы белән бәйләп карый [1: 55].

Р.Идиятуллин, кайда гына яшәп иҗат итүләренә карамастан, Башкортстан төбәгеннән чыккан шагыйрьләр шигъриятендә чагылган гомум сыйфатларны, бер яктан, культура-тарих мәктәбе традицияләрендәгечә, төбәк табигате һәм мохитенең тәэсире белән аңлатса, икенче яктан, башкорт җырларының илаһи аһәңе, дала киңлеге, таулар горурлыгы, сүз тәме һәм хис нечкәлеге белән нисбәтле бәйләнештә карый [16: 55]. Бу позиция күкрәгендә шигырь уты янган С.Рәхмәтулла тарафыннан яклау тапса [17: 45], яшь тәнкыйтьче Р.Сөләйманов татар шагыйрьләренең әсәрләрендә ике мәдәният йогынтысы барлыгын билгели һәм төбәк шигъриятенең Татарстан поэзиясеннән үзгә сыйфатлары барлыгын әйтеп уза [18: 51].

«Төбәкнең географик, тарихи үзгәлеге чагылу»ны, «туган җир һәм туган тел тойгысына зур игътибар» бирелүне, «ватандарлык төшенчәсе яңа бизәкләр белән баетылу»ны Р.Идрисов Башкортстандагы татар шигъриятенә хас үзенчәлекләр буларак аерып чыгара. «Төбәк үзенчәлеге тема сайлауда, геройлар даирәсендә, сурәтләү чаралары һәм менталитетка нигезләнгән дөньяның тел картинасында үзен сиздереп тора. Башкортстан татар поэзиясенә С.Юлаев, Акмулла, Ш.Бабич, М.Гафури образлары рухи ориентирлар ролен уйный. Агыйдел, Урал, туган авыл исемнәре «кече Ватан» төшенчәсен бирә» [19: 63], – дип яза ул. Галим фикеренчә, төбәк шигъриятенең үзгә яңгырашы Башкортстан татарлары «менталитетына гына хас үзенчәлекләр», «башкорт халкы белән хуҗалык итүдәге хезмәттәшлек, мәдәни багланышлар, туганлык җепләре, көнкүрештәге берлек, телләр якынлыгы» һәм «Башкортстанга күчеп утыручы татарларның пассионарлык куәте» белән тәэмин ителә.

Үзешчән шагыйрә М.Гыйльманова Башкортстандагы татар шигъриятенең үзенчәлеген, беренче чиратта, «иҗтимагый-сәяси һава торышы» белән аңлатып, «безнең шагыйрьләр фикерләрен саграк ача, бик тугарылып бармыйлар. Алар бар теләгән нәрсәләрен, үзләренең уй-фикерләрен язып чыгара алмыйлар» [20: 59], – дип ассызыклый. М.Вафин исә төбәк шигъриятенең үзенчәлеген «географик-топонимик үзгәлек», психологиядә, милли үзаңдагы аерымлыклар, шулай ук тарихи, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни шартлар белән сәбәпле бәйләнештә карый [21: 63].

Башкортстандагы татар поэзиясен гомумтатар шигъриятеннән аерып, аны, үзендә татар һәм башкорт менталитетын берләштереп, ике арада «күпер» булган мөстәкыйль агым, хәтта мөстәкыйль әдәбият дип бәяләү әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан тулысынча яклау тапмады. Шагыйрь һәм прозаик Р.Сабит бу

позицияне кире кагып, болай дип яза: «…Башкортстан татарлары белән Казан татарлары шигъриятендә әллә ни аерма күрмим. Безнең иҗатыбыз – зур шигърият һәм нindидер төбәк поэзиясе булып кала алмый» [22: 63]. Мәкалә авторы, кайсы төбәкләрдә яшәүгә карамастан, татар халкының бердәмлеген яклый.

Әлеге карашны татар әдәбиятында шартлы романтик стильдә иҗат ителгән проза әсәрләре авторы буларак танылган М.Кәбиров та куәтли: «Милләт бер ул. Татарның Казанда яшәгәне дә, Мәскәүдә яшәгәне дә «татар» дип атала. Милләтне милләт итеп тотучы көч – мәдәният. Ә мәдәниятнең нигезендә әдәбият тора. Шуңа күрә минем әдәбиятны җирлекләргә бүлгәлисем килми. «Башкортстан татарлары әдәбияты» дип әйтү дә, «Казан татарлары әдәбияты» дип әйтү дә дөрес түгел. Татар әдәбияты бар, һәм ул – бербөтен. <…> Язучының зурлыгы кайда тууы һәм кайда яшәве белән билгеләнми. <…>. Иң мөһиме – шәхес үзенчәлеге» [23: 58-59].

Төбәк татар әдәбияты һәм, шул исәптән, поэзиясе хасиятләре проблемасына багышланган бәхәстә «Башкортстан татар әдәбияты», «Башкортстан татарлары» төшенчәләренең дә үтә шартлылыгы билгеләнде. «Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Ырымбур һ.б. республика-өлкәләрдә яшәүче милләттәшләребез уртак бер этнос – «Идел-Урал буе татарлары» исеме астында берләштерелә. Безнең телебез дә, динебез дә, әдәбиятыбыз да, көй-моңнарыбыз да, йөз төзелешебез дә, хәтта ки йорт салу, хуҗалык итү рәвешебез дә бер үк. Шулай булгач, «Башкортстанда яшәүче татарлар», «Башкортстандагы татар әдәбияты», «Башкортстандагы татар шигърияте» дигән терминнарны куллану дөресрәк булыр» [24: 36], – дигән фикердә тора И.Фазлетдинов.

Аерым гыйльми даирәләрнең «Башкортстандагы татар шигърияте татар әдәбиятыннан фикер тирәнлеген, башкорт шигъриятеннән хисләр киңлеген алган, шул рәвешле, үзенчәлекле аһәң, моң барлыкка килгән» дигән фикере дә каршылыклы. «…Уйланып карыйк. Татар хиссез, йөрәксез, салкын акыл белән генә яшәүче кавем булып чыгамыни?! Алай булгач, хис белән мөлдерәмә тулы «Ак калфагым төшердем кулдан», «Әдрән диңгез», «Сарман», «Шахта көе» кебек халык җырларыбыз ничек туган? Мәшһүр Тукаебыз, Такташыбыз, Туфаныбыз хиссез шагыйрьләрмени? Алай булгач, ник бөтен төрки халыклар аларга табына, үзләренең остазлары, кыйблалары дип исәпли? Башкортстанны гомеренең азагында гына килеп күргән Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәтләрдә меңнәрчә «хиссез татар» утырган Казан залларын елатырлык хис каян килгән? <…> Хиссез милләт булмаган кебек, хиссез шигърият тә була алмый. Шигырьдәге хис тамырларын, халыкның күңеленнән, рухиятеннән, ерак тарихыннан, милли фольклорыбыздан эзләргә кирәк» [24: 36-37]. Язма авторы Башкортстанда яшәүче татар шагыйрьләре белән Татарстан шагыйрьләре иҗаты арасында тематикада, идея-эстетик эчтәлектә, поэтик рухта зур аермалар булмавын ассызыклый. М.Вафин һәм Л.Сәгыйдуллиналар иҗатында киң чагылыш тапкан «илле-илсезлек, телле-телсезлек, Ватанлы-Ватансызлык» мотивының чагылышын Казан шагыйрьләре – Г.Морат белән Р.Зәйдуллада күзәтелүен билгели һәм шигырьнең аһәңен-моңын географик чикләр белән генә аңлатуның дөреслеккә туры килмәвен яза: «Моның сәбәпләре тирәндәрәк – шагыйрьләребезнең күңелләрендә ята. Зөлфәт Хәким сүзләре белән әйтсәк, “хроник ирексезлек – бөтен татар халкына куелган диагноз ул!” Ә шигърият, Казанныкымы ул, әллә Уфаныкыны – шушы гомум милләткә куелган диагнозның бер чагылышы гына…» [24: 36-37]. Мәкаләдә, төбәк шигъриятен гомумтатар поэзиясеннән аерып карау тенденциясеннән баш тартып, шагыйрьләрнең стиль үзенчәлекләрен ачыклауга игътибарны көчәйтү фикере ассызыклана.

К.Дәүләтшин Башкортстандагы татар шигъриятен гомумтатар поэзиясеннән аерып торган бер үзенчәлекне иҗат юнәлешендә күреп, аны «кырыс реализмның романтика белән тыгыз үрелгән бер төре» дип атаса да [8: 8], бу караш та бәхәсле. Тикшеренүчеләр билгеләвенчә, татар әдәбиятында «XX йөз ахыры – XXI йөз башында да реалистик катламнар белән баетылган романтик әсәрләр язылу дәвам итә. <…> …Җәмгыятьнең кешегә дошманлыгы белән олы мәхәббәт тарихлары кушылып, романтик реализм агымындагы әсәрләр туа» [25: 81]. Күренә ки, ул – Башкортстандагы татар шигъриятенә генә түгел, ә гасыр чигендәге бөтен татар әдәбиятына хас сыйфат.

Р.Әмиров төбәк шагыйрьләрен, образлы фикерләүгә мөрәҗәгать итеп, «күрше утарга

ябылган тышаулы ат»ларга тиңли һәм төбәк шигъриятенең бер үзенчәлеген эш аты образының гаять көчле яңгыраш алуында күрә. «Авызлык, йөгән, тышау, тәртә, чыбыркы кебек һәркемгә таныш әйберләр аша Башкортстан шартларында гомер итүче татар образы ачыла. <…>. Димәк, Тукай әсәрендәге *(«Без тынычта аттан артык эшлибез»)* ат образының эш аты рәвешен алуы табигый һәм тарихи яктан аңлашыла» [26:46], – дип яза әдәбият галиме. Р.Әмиров эзләнүләрендә әдәби, поэтик анализ принциплары түгел, ә бәяләү объектына сәяси-социологик ноктадан якын килү өстенлек итә. Тышаулы ат образы, җирле шагыйрьләрнең иҗат үзенчәлекләреннән дә бигрәк Башкортстанда 2000 елларда хөкем сөргән сәяси вәзгыятькә бәя бирү сәбәпле, хәзерге иҗтимагый шартларда элекке актуальлеген югалтып бара.

Яшь тәнкыйтьче Л.Ваһапова эшчәнлегендә Башкортстан татар шигъриятен системалы итеп тикшерү үрнәге күзәтелә. Ул җирле поэзия шагыйрьләренең иҗат йөзен билгеләгән үзенчәлекләрне аерып чыгара. Аның карашынча, М.Закиров шигърияте гадилеге, халыкчанлыгы белән аерыла һәм, гадилектән катлаулыга барып, фәлсәфилеккә ирешү аның иҗатының бер үзенчәлеге булып тора. Тормыш фәлсәфәсен барлык тирәнлегендә ачып, гомумиләштерүләр аша, мәгънә тыгызлыгына ирешү – С.Рәхмәтулла иҗатына хас сыйфатлар. И.Фазлетдинов шигърияте, халыкчан образлар белән фәлсәфилеккә йөз тотып, үткәннәр белән тыгыз бәйләнештә торган һәм бүгенге өчен җаваплылык хисен югалтмый яшәүче кешенең күңел дөньясына үтеп керү, шәхеснең рухи халәтен табигый камиллегендә сурәтләргә омтылу белән аерылып тора. Поэтик образ тудыру остасы, кыю фикерле, кинаяле, бунтарь шагыйрь М.Вафин әсәрләрендәге гаҗәеп сагышлы моң, парадоксаль фикерләр, көтелмәгән мәгънәви борылышлар ясау кебек хасиятләр күрсәтелә. Л.Сәгыйдуллина лирикасын мәкалә авторы төбәк шигъриятендәге модернистик эзләнүләр яссылылында бәяләргә омтыла. Аның фикеренчә, шагыйрә дөньяны архаик мифологик символлар аша билгеләнгән Мәңгелеккә омтылыш төсле күзаллый. Мәңгелек һәм Инсан, үткән һәм бүгенге, киләчәк һәм билгесезлек, Җир һәм Күк мөнәсәбәте бу иҗатның асылын билгели. Дөньяны экзистенциаль тоемлау, чишелеш эзләп бәргәләнү, үз-үзеңә сорау бирү, җавап таба алмый тышкы дөньяга мөрәҗәгать итү бу иҗатта еш очрый. Җирле шигърияттә әдәплелеге, рух ныклыгы белән аерым урын биләп, әсәрләрендә туган җир һәм балачак темалары гәүдәләнгән Ф.Габидулинаның иҗади каләменә динамика, сурәтләнгән предметның эченә үтеп керү; түземлек, каршылыклар аша яңа эчке халәткә ирешкән, тыенкы җан образы иҗат итү хас [7: 104-108].

Дөнья әдәбиятын төрле төстәге хуш исле, гүзәл чәчәкләргә күмелеп утырган ямьле болынга тиңләргә мөмкин. Татар әдәбияты шушы болындагы матур бер чәчәккә тиң булса, Башкортстандагы татар әдәбияты – шуның бер таҗы. Бу төбәк милли сүз сәнгатен гасырлар буена, индивидуаль үзенчәлекләре булса да, татар поэзиясенең гомуми үсеш сукмагыннан аерылмаган иҗат көчләре белән туендырып торган. Җәмгыяви-сәяси җилләр аерым чорларда, иҗат көчләрен бер-берсеннән аерылырга мәҗбүр итсә дә, җирле шигърият бүленмәс татар халкының рухи-мәдәни байлыгы һәм казанышы булып торуы төбәк әдәби тәнкыйте тарафыннан раслана.

**Әдәбият**


1. *Габдерәхим Ф.* Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен… // Тулпар. 2006. №1 (70). Б. 54-55.
2. *Морзакаева Д.* Милли китап: Зәйнәп Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшриятында милли басмалар нәшерләү һәм биредә дөнья күргән китаплар хакында. Уфа, 2012. 152 б.
3. *Сафуанов С.* Рухи күперләр. Уфа: Китап, 2006. 376 б.
4. *Галимуллин Ф.* Табигыйлеккә хилафлык: XX гасырның егерменче-утызынчы елларында татар әдәбиятының үсеш үзенчәлекләре. Казан: Мәгариф, 2004. 303 б.
5. *Сибәгатов Р.Г.* Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. Казан: Мәгариф, 2002. 191 б.
6. *Морзакаева Д.* Исә Болгар җилләре… // Тулпар. 2006. №2 (71). Б. 56-59.
7. *Ваһапова Л.* Башкортстандагы хәзерге татар әдәбияты // Чын мирас. 2013. №5 (17). Б. 103-110.
8. *Дәүләтшин К.* Туган як шигърияте. Индивидуаль стиль һәм поэтик образлылык мәсьәләләре: уку әсбабы. Уфа: БДУ нәшр., 2002. 108 б.
9. *Хафизов С., Вафин М.* Туган җир музасы: Башкортстанда яшәүче татар телле шагыйрьләр иҗаты турында «кырлы» өстәл // Тулпар. 2001. №1 (40). Б. 23-29.
10. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

11. *Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2000. 351 б.
12. Атнабай – Халык шагыйре. Уфа: Башкортстан Республикасы «Рухият» фонды, 2000. 399 б.
13. *Сәгыйдуллина Л.* Абага чәчәге // Биш кыллы саз: шигырьләр. Уфа: Башкортстан «Китап» нәшр., 2001. Б. 301-399.
14. Сөйләшүгә чакырабыз // Тулпар. 2006. №1 (70). 54 б.
15. Бәхәс тәмам // Тулпар. 2007. №6 (81). Б. 36-37.
16. *Идиятуллин Р.* Татар барда, шигырь бар! // Тулпар. 2006. №2 (71). Б. 47.
17. *Рәхмәтулла С.* Уйланырга урын бар… // Тулпар. 2006. №4 (73). Б. 48-49.
18. *Сөләйманов Р.* Барысы да үзебезнең кулда… // Тулпар. 2006. №5 (74). Б. 51.
19. *Идрисов Р.* Туган якның әдәби сурәте // Тулпар. 2007. №1 (76). Б. 62-63.
20. *Гыйльманова М.* Кайда берлек, шунда көч! // Тулпар. 2007. №4 (79). Б. 59.
21. *Вафин М.* Үсәргә дә әле үсәргә… // Тулпар. 2007. №5 (80). Б. 62-63.
22. *Сабит Р.* Татар шигърияте үсештә // Тулпар. 2006. №3 (72). Б. 33.
23. *Кәбиров М.* Шагыйрьләр кабатланмый // Тулпар. 2007. №4 (79). Б.58-59.
24. *Фазлетдинов И.* Бүленгәнне бүре ашар… // Тулпар. 2007. №3 (78). Б. 36-38.
25. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш.Гыйлаҗев, Н.М. Йосыпова. Казан: Мәгариф, 2006. 319 б.
26. *Әмиров Р.* «Без тынычта аттан артык эшлибез…»: Тукай иҗаты һәм Башкортстандагы татар шигърияте // Тулпар. 2011. №6 (105). Б. 44-46.

---

# СОВРЕМЕННАЯ ТАТАРСКАЯ ПОЭЗИЯ БАШКОРТОСТАНА В ЗЕРКАЛЕ КРИТИКИ

**Ильдус Камилович Фазлутдинов,**
Башкирский государственный университет,
Россия, 450076, г. Уфа, ул. Заки Валиди, д. 32,
fazlutdinov75@mail.ru.

В статье на основе изучения отзывов критиков дана картина развития современной татарской поэзии Башкортостана, выявлены особенности поэтического мира авторов произведений. Новизна исследования заключается в том, что впервые, благодаря систематизации научно-критических материалов (Р.Сибгатов, К.Давлетшин, С.Сафуанов, Р.Амиров, М.Мулюков, С.Хафизов, Р.Идрисов, И.Фазлетдинов, Л.Вагапова и др.), определяются ключевые тенденции в развитии современной татарской поэзии Башкортостана. Во вступительной части татарская литература, в том числе и поэзия Башкортостана, изучается в социокультурном ключе, охарактеризованы особенности самоопределения татарских поэтов, которые идентифицировали себя в плоскости либо татарской, либо башкирской литератур, названы исторические предпосылки данного раскола, определена степень влияния этого процесса на творчество поэтов. Внимание автора сосредоточено на теоретическом осмыслении проблемы стилистических особенностей творчества, для чего конкретизируются различия между понятиями «стиль», «индивидуальный стиль», «региональные особенности стиля». Эта работа осуществляется на основе классификации, принятой в литературоведении. Исследователь стремится раскрыть особенности картины мира, художественного отображения современности в произведениях, выявить характерные черты мышления поэтов, их эстетической позиции. Объектом внимания выступает творчество Ф.Габдерахима, Р.Идиятуллина, С.Рахматуллы, Р.Гатауллина, Л.Сагидуллина, М.Вафина и др. Автор статьи на основе анализа идейно-художественного своеобразия проблематики стихотворений, ключевых мотивов выявляет их эстетическую ценность, роль тысячелетней поэтической традиции и новаторство поэтов, чье творчество превращается в общее достояние татарской культуры.

**Ключевые слова**: поэзия, творчество, индивидуальный стиль, литературная критика, Башкортостан, творческий метод, поэтический образ, символ.